**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№5336**
**19.09.2018**

Башкарма комитетның 2016 елның 3 ноябрендәге 5793 нче карары белән расланган 2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү программасына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсе, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ санлы Законы, шәһәр Уставының 41 маддәсе, Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнарының гражданнарның аерым категорияләренә өстәмә социаль ярдәм чаралары һәм социаль ярдәм күрсәтүгә хокукларын тормышка ашыру турында» 2009 елның 9 апрелендәге 40/17 нче карары, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 нчы карары нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2016 елның 3 ноябрендәге 5793 нче карары белән (Башкарма комитетның 2017 елның 10 мартындагы 1182 нче, 2017 елның 14 апрелендәге 2234 нче, 2017 елның 24 июлендәге 4318 нче, 2017 елның 25 сентябрендәге 5702 нче, 2017 елның 27 сентябрендәге 5755 нче, 2017 елның 23 ноябрендәге 7195 нче, 2017 елның 7 декабрендәге 7601 нче, 2018 елның 8 августындагы 4481 нче карарлары редакциясендә) расланган 2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7 бүлекнең II бүлекчәсендә «Бәйрәм һәм истәлекле даталарга багышланган чаралар оештыру һәм үткәрү»:

1 пунктта «2018 ел (мең сум)» баганасындагы «104,0» цифрларын «89,0» цифрларына алмаштырырга;

5 пунктта «2018 ел (мең сум)» баганасындагы «158,0» цифрларын «157,0» цифрларына алмаштырырга;

8 пунктта «2018 ел (мең сум)» баганасындагы «210,0» цифрларын «211,0» цифрларына алмаштырырга;

«Барлыгы» юлында «2018 ел (мең сум)» баганасындагы «882,0» цифрларын «867,0» цифрларына алмаштырырга;

2) 7 бүлекнең IV бүлекчәсендә «Аз тәэмин ителгән балалы гаиләләргә социаль ярдәм чараларын тормышка ашыру»:

1 пунктта «2018 ел (мең сум)» баганасындагы «1014,0» цифрларын «1029,0» цифрларына алмаштырырга;

«Барлыгы» юлында «2018 ел (мең сум)» баганасындагы «1866,0» цифрларын «1881,0» цифрларына алмаштырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин